**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**02.09.2019** **№ 1478**

**Ятим балалар оешмаларында тәрбияләнүче балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү турында”, 2018 елның 19 июлендәге 204-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының “Ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны опекага (попечительлеккә), тәрбиягә алырга яки патронат гаиләгә уллыкка (кызлыкка) алырга ниятләүче гражданнарга медицина тикшерүе узу тәртибен раслау, шулай ук андый гражданнарның медицина тикшерүе узу нәтиҗәләре турында бәяләмә формасы турында”, 2014 елның 18 июнендәге 290н номерлы Боерыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының “Ятим балалар оешмаларында тәрбияләнүче балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге буенча аерым мәсьәләләрне тормышка ашыру турында”, 2019 елның 16 гыйнварындагы 17 номерлы Боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 4 июнендәге 1169 номерлы карары белән расланган “Ятим балалар оешмаларында тәрбияләнүче балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына” түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.5.2 пунктының б пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) Гражданин белән бергә торучы аның гаилә әгъзаларында ачык формада инфекцион авырулар, психик тайпылышлар һәм үз-үзен тотуда тайпылышлар диспансер күзәтүе туктатылганчы булмавы турында дәвалау-профилактика учреждениясе белешмәсе. Белешмә урынына гражданинның гаилә әгъзалары 164/у формасында, дәвалау-профилактика учреждениесе биргән медицина бәяләмәсен тәкъдим итәргә мөмкиннәр (2 нче кушымта).

Күрсәтелгән документлар опека һәм попечительлек органы тарафыннан, аларны биргән датадан 6 ай дәвамында кабул ителә;»;

2) 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының,

яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү буенча функцияләрне тормышка ашыручы оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) гариза бирүченең судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү предметы.

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен тәкъдим итүдә катнашучы опека һәм попечительлек органы хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр шикаять белән Башкарма комитетка, Башкарма комитет җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) муниципаль берәмлек Советына шикаять белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять закон белән билгеләнгән тәртиптә шикаять ителә.

5.2. Гариза бирүче шикаять белән шул исәптән түбәндәге очракларда да мөрәҗәгать итә ала:

1) 210-ФЗ Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән сорату, дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратуның теркәү срогын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү турында сорату теркәүнең срогын бозу. Күрсәтелгән очракта, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре гамәлләренә (гамәл кылмауларына) гариза бирүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган  күпфункцияле үзәккә билгеле дәүләт яки муниципаль хезмәтне тулы итеп, 2010 ел, 27 нче июль 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 нчы статьясы 1.3 бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта гына мөмкин;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерацисе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларында  каралмаган өстәмә  документлар  яки мәгълүмат яисә эшчәнлек таләп итү;

4) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда  күздә тотылган документларны кабул итүне кире кагу;

5) федераль законнар, федераль законнар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка төр норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында кире кагу өчен җирлек булмаган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту. Күрсәтелгән очракта, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре гамәлләренә (гамәл кылмауларына) гариза бирүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган  күпфункцияле үзәккә билгеле муниципаль хезмәтне тулы итеп 2010 ел, 27 нче июль 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 нчы статьясы 1.3 бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта гына мөмкин;

6) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәткән очракта Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында  каралмаган түләү таләп итү;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче  органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче  органның вазыйфаи  затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә  күздә тотылган оешмаларның, яки аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә документларда алар җибәргән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту, яисә андый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозган очракта. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү

карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин;

8) дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирүнең срогын һәм тәртибен бозу;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору, әгәр дә федераль законнар, алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка төр норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында моның өчен нигез булмаса. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәтләре күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин;

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән беренче тапкыр дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта кирәкле булган документларны кире какканда аларның юклыгы һәм (яки) тулы булмаганлыгы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматларны таләп итү, яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы 1 бүлеге 4 пунктында каралган очраклардан кала муниципаль хезмәтне күрсәтү. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәте күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәтен алучы шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматларны алырга хокуклы.

5.4. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон формада җибәрелә.

Шикаять почта, күпфункцияле үзәк, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре, Биектау муниципаль районы рәсми сайты (http://vysokaya-gora.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү почта, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (функцияләр), шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы “г” бүлегендә каралган оешмалар һәм шулай ук аларның хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү почта, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре, әлеге оешмаларның рәсми сайтлары, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (функцияләр), шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.5. Шикаятьне карау срогы – аны теркәгән көннән башлап, унбиш эш көне дәвамында. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының кире кагуын шикаять иткән очракта, күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмалар гариза бирүчедән документларны кабул итүдән баш тарткан яисә җибәрелгән ялгышларны һәм хәреф-хаталарын төзәтүдә яки әлеге төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозган вакытта - аны теркәгән көннән

башлап, биш эш көне дәвамында.
5.6. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:
1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелүче дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, муниципаль хезмәте күрсәтү органы, дәүләт хезмәте күрсәтү яки муниципаль хезмәт күрсәтү органы вазыйфаи затының, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесе һәм (яки) хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә каралган оешмалар, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) аларның хезмәткәрләренең исемнәре;
2) гариза бирүчегә җавап бирү өчен фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы булган очракта), гариза бирүченең яшәү урыны турында белешмә – физик затның яисә исеме, гариза бирүче юридик затның урнашкан урыны турында белешмә, хәбәрләшү өчен телефон номеры, электрон почта адресы (адреслары) (ахыргысы булган очракта) һәм почта адресы;
3) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелүче дәүләт хезмәте күрсәтү органы, дәүләт хезмәте күрсәтү органы вазыйфаи заты, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмалар, аларның хезмәткәрләре турында мәгълүматлар;
4) дәүләт хезмәте күрсәтү органы, дәүләт хезмәте күрсәтү органы вазыйфаи заты, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмалар, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) дәлилләре белән гариза бирүче килешмәү нигезендә.
5.7. Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар, яисә аларның күчермәләрен тәкъдим ителә ала (булган очракта).
5.8. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча, түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:
1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны кире кагу формасында, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән гаризаны кертү вакытында җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү буенча төзәтмәләрне, гариза бирүчегә акчалата чараларны кире кайтару, ләкин акча алу Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә каралмаган;
2) шикаять канәгатьләндерелүдән баш тартыла.
Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгәннең икенче көннән үк соңга калмыйча, гариза бирүчегә язма рәвештә, теләге булган очракта электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре күрсәтелгән дәлилләнгән җавап хаты җибәрелә.
5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта гариза бирүчегә җибәрелә торган җавапта дәүләт хезмәте күрсәтү вакытында ачыкланган кагыйдә бозулар кичекмәстән юкка чыгару өчен дәүләт хезмәте күрсәтү органының, күпфункцияле үзәкнең, яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмаларның эшчәнлекләре турында мәгълүмат бирелә, шулай ук гариза бирүчедән китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу сорала һәм киләчәктә дәүләт хезмәте алу максатларында гариза бирүче эшләргә тиешле эшчәнлек турында мәгълүмат күрсәтелә.
5.10. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләрен аңлатып нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.
5.11. Карарны кабул итү барышында яки шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки вазыйфаи зат тарафыннан хокук бозу очраклары булу мөмкинлеге ачыкланса, шикаятьятләрне карау буенча вәкаләтләргә ия булган хезмәткәр барлык материалларны прокуратура органнарына җибәрелә.”
3) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«1 нче кушымта**
**Ятим балалар оешмаларында тәрбияләнүче балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә яшәүче балигъ булган граждannar гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына**

Опека һәм попечительлек органына

___________________________________
(фамилия, исем, әтисенең исеме (булган очракта)

Гражданинның опека һәм попечительлек органыннан баланы (балаларны) вакытлыча гаиләгә бирү мөмкинлеге турында бәяләмә бирү турында гаризасы

Мин, ___________________________________________________________
(фамилия, исем, әтисенең исеме (булган очракта), шул исәптә алда булганы, баш килештә)

_____________________________________________________________
(көн, ай, ел һәм туган урыны)

Гражданлык_____________ Шәхесне ачыклаучы документ: _________________________

_____________________________________________________________
(серия, номер, кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)

Яшәү урыны адресы ___________________________________________

_____________________________________________________________
(тулы итеп яшәү урыны адресы, яшәү урынында теркәлү белән расланып күрсәтелә, ул булмаган очракта сызык куела)

_____________________________________________________________

Тору урыны адресы ___________________________________________

_____________________________________________________________
(әгәр дә теркәү белән расланган тору урыны булган очракта тутырыла, шул исәптән теркәлү белән расланган яшәү урыны булган очракта да. Тулы тору урыны адресы күрсәтелә, ул булмаган очракта сызык куела)

Фактта яшәү урыны адресы ______________________________________

_____________________________________________________________
(әгәр дә фактта яшәү урыны адресы яшәү урыны адресы яки тору урыны адресы белән туры килмәсә яисә теркәү белән расланмаган яшәү урыны һәм тору урыны булмаганда тутырыла)

_____________________________________________________________
(элек яшәгән, шул исәптән Совет Армиясе, Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә хезмәт узган, укыган Россия Федерациясе субъектларын күрсәтергә)

Телефон номеры_______________________________________________
(булган очракта күрсәтелә)

Хөкемгә тартылу булу (булмавы) һәм (яки) җинаять эзәрлекләве факты булу (булмавы) турында мәгълүматлар :

☐ хөкем ителмәдем һәм шәхеснең тормышы һәм сәламәтлеге, ирегә, намусы һәм абруена, шәхеснең җенси кагылгысызлыгы һәм җенси ирегенә карата, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка карата, шулай ук иҗтимагый имнилеккә, тынычлыкка һәм кешелек иминлегенә карата җинаять кылмадым

☐ шәхеснең тормышы һәм сәламәтлеге, ирекгә, намусы һәм абруена, шәхеснең җенси кагылгысызлыгы һәм җенси ирегенә карата, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга, халыкның сәламәтләгенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка карата, шулай ук иҗтимагый имнилеккә, тынычлыкка һәм кешелек иминлеге өчен җинаять эзэрлекләвенә дучар булмадым һәм түгел

☐ авыр һәм аеруча да авыр җинаятьләр өчен акланмаган һәм бетерелмәгән хөкемем юк

Гражданинның яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында мәгълүматлар

| № | Фамилия, исем, әтисенең исеме (булган очракта) | Туган елы | Балага карата туганлык мөнәсәбәте | Кайсы вакыттан теркәлгән һәм яши |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

☐ миңа гаиләгә баланы (балаларны) вакытлыча тапшыру мөмкинлеге булу турында бәяләмә бирүегезне сорыйм

☐ миңа гаиләгә баланы (балаларны) вакытлыча тапшыру мөмкинлеге булу турында бәяләмә бирүегезне сорыйм

______________________________________________
(баланың (балаларның) фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), туган көне, ае, елы)

______________________________________________

Торак шартларым, сәламәтлегем һәм хезмәт характеры миңа баланы (балаларны) үз гаиләмә вакытлыча алырга мөмкинлек бирә.

Үзем турында өстәмә түбәндәгеләрне хәбәр итә алам:

______________________________________________
(гражданинның балаларны тәрбияләүдә кирәкле белемнәре һәм күнекмәләре булуы, һөнәри эшчәнлек турында, Россия Федерациясе территориясендә ата-ана тәртиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә кабул итәргә теләүче затларны әзерләү узу турында мәгълүматлар күрсәтелә)

______________________________________________

Мин, ______________________________________________,
(фамилия, исем, әтисенең исеме (булган очракта)

әлеге гаризада һәм минем тарафтан тәкъдим ителгән документларда булган минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртү һәм куллануга ризалыгымны бирәм.

______________________________________________

______________________________________________

Гаризага түбәндәге документларны терким:

☐ шәхесне раслаучы документ күчермәсе

☐ дәвалау-профилактика медицина учреждениесенең ачык формада инфекцион авырулар яки психик авырулар, наркомания, токсикомания, эчкечелек булмавы турында бәяләмә яисә 164/у формасы буенча бәялэм (ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны уллыкка (кызлыкка) алырга, опекага (попечительлеккә), тәрбиягә алырга яки патронат гаиләгә алырга ниятлгән гражданинның медицина тикшерүе нәтиҗәләре турында бәяләмә)*

Башка документлар:
1.
2.
3.

---

* Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының “Ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны опекага (попечительлеккә), тәрбиягә алырга яки патронат гаиләгә уллыкка (кызлыкка) алырга ниятләүче гражданнарга медицина тикшерүе узу тәртибен раслау, шулай ук андый гражданнарның медицина тикшерүе узу нәтиҗәләре турында бәяләмә формасы турында”, 2014 елның 18 июнендәге 290н номерлы Боерыгы (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының 2014 елның 28 июлендә теркәлгән, теркәү номеры 33306)»;

4) 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«3 нче кушымта**
**Ятим балалар оешмаларында тәрбияләнүче балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына**

Форма

Опека һәм
попечительлек органы
бланкы

Актны төзү датасы

Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яшәүче гражданинның яшәү шартларын тикшерү акты

Тикшерү датасы «___» __________ 20___ ел
Тикшерү уздырган вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта) __________
________________________________________

Яшәү шартларын тикшерү уздырылды ______________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, (булган очракта), туу датасы)
________________________________________

Шәхесне раслаучы документ ______________________________
________________________________________
(серия, номер, кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)

Туу датасы һәм урыны ______________________________
Яшәү урыны адресы ______________________________
(теркәү белән расланган яшәү урыны адресы)
________________________________________

Адрес места фактического проживания и проведения обследования ____________________

________________________________________

(әгәр дә фактта яшәү урыны адресы яшәү урыны адресы яки тору урыны адресы белән туры килмәсә яисә теркәү белән расланмаган яшәү урыны һәм тору урыны булмаганда тутырыла)

Белем ____________________

Һөнәри эшчәнлек ____________________

________________________________________

(эш урыны, адрес, били торган вазыйфа, эш телефонын күрсәтеп)

Торак урын, биредә яши ____________________,

(фамилия, исем, әтисенең исеме (булган очракта)

тәшкил итә _______ кв. м, тора ____________________ бүлмәдән, һәрбер бүлмәнең күләме:

_______ кв. м, _______ кв. м, _______ кв. м, _______ катта _______ катлы өйдә.

Өйнең сыйфаты (шул исәптән, кирпеч, панель, агач; нормаль халәттә, тузган, авария хәлендә; бүлмәләр коры, якты, үтеп йөри торган, тәрәзәләр саны)

________________________________________

________________________________________

________________________________________

Өйне һәм торак мәйданны төзекләндерү (шул исәптән, канализация, нинди җылыту, газ, юыну, лифт, телефон) ____________________

________________________________________

Торак бинаның милекчесе (яллаучысы) булып тора ____________________

________________________________________

________________________________________

(фамилия, исем, әтисенең исеме ( булган очракта), гражданинга карата туганлык дәрәҗәсе)

Торак бина белән куллану хокукын раслаучы нигезләр, торак бина белән куллану хокукы срогы ____________________

________________________________________

(торак бина башка затлар милкендә булган очракта тутырыла)

Торак бинаның санитар-гигиеник халәте (яхшы, канәгатьләнерлек, канәгатьләндерерлек түгел): ____________________

Бала өчен аерым бүлмә, почмак, йокы, уен, күнекмәләр, шәхси әйберләр өчен урын булуы

________________________________________

________________________________________

Торак бинада яшиләр (гражданинның яшәү урыны буенча теркәлгән һәм (яки) фактта яшәүчеләр):

| Фамилия, исем, әтисенең исеме (булган очракта) | Туган елы | Эшләү урыны, вазыйфа яки уку урыны | Туганлык мөнәсәбәтләре | Әлеге торак бинада кайсы вакыттан бирле яши |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

Гражданинның гаилә әгъзалары арасында килеп туган мөнәсәбәтләр ____________________

(шул исәптән гаилә әгъзалары арасында үзара мөнәсәбәтләрнең характеры, балалар белән аралашу, балаларның үзара аралашу үзенчәлекләре)

Гражданинның баланы (балаларны) үз гаиләсенә вакытлыча тапшыру өчен мотивлары

Тикшерүнең өстәмә мәгълүматлары (шул исәптән, состав, яшьләрен күрсәтеп балаларның булуы, балалар белән аралашу тәҗрибәсе, гаилә әгъзалары арасында үзара мөнәсәбәтләр, якын туганнарның булуы һәм аларның гаиләгә баланы (балаларны) вакытлыча тапшыруга карата мөнәсәбәте;
гражданин гаиләсенә башка балаларны вакытлыча урнаштыру тәҗрибәсе;
гражданинның балалар тәрбияләүдә кирәкле белемнәре һәм күнекмәләре булуы;
опека һәм попечительлек органының гражданинның уллыкка алучы яки опекун (попечитель) була алу мөмкинлеге турында бәяләмә;
Россия Федерациясе территориясендә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләгән затларның әзерлек узуы, гражданинны психологик яктан тикшерү турында мәгълүмат)

Гражданинның яшәү шартлары

(канәгатьләндерерлек/ канәгатьләндерерлек түгел, конкрет хәлләрне күрсәтеп)

Тикшерү уздырган затның имзасы

| | | |
|---|---|---|
| (Россия Федерациясе субъекты опека һәм попечительлек органының яки җирле үзидарә органының вәкаләтле вазыйфаи заты (әгәр дә Россия Федерациясе субъекты законнары белән җирле үзидарә органнары федераль законнар нигезендә опека һәм попечительлек буенча вәкаләтләр тапшырылган булса) | (имза) | (Ф.И.О.) |

5) 4 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«4 нче кушымта**
**Ятим балалар оешмаларында тәрбияләнүче балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә яшәүче балигъ булган граждannар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына**

Форма

Опека һәм попечительлек органы бланкы

Бәяләмә төзү датасы

Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданин гаиләсенә
баланы (балаларны) вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында
опека һәм попечительлек органы
бәяләмәсе

Фамилия, исем, әтисенең исеме (булган очракта) ______

Туу датасы ______

Яшәү урыны адресы ______

(теркәү белән расланган яшәү урыны адресы)

______

Факттагы яшәү урыны адресы ______

______

(әгәр дә фактта яшәү урыны адресы яшәү урыны адресы яки тору урыны адресы белән туры килмәсә яисә теркәү белән расланмаган яшәү урыны һәм тору урыны булмаганда тутырыла)

Гаиләнең тасвирламасы (шул исәптән, яшьләрен күрсәтеп балаларның булуы, балалар белән аралашу тәҗрибәсе, гаилә әгъзалары арасында үзара мөнәсәбәтләр, якын туганнарның булуы һәм аларның гаиләгә баланы (балаларны) вакытлыча тапшыруга карата мөнәсәбәте) ______

______

______

______

Белем һәм һөнәри эшчәнлек ______

Сәламәтлек халәте тасвирламасы (гомуми сәламәтлек халәте, баланы (балаларны) гаиләгә вакытлыча тапшыруга тоткарлык итүче авырулар булмавы) ______

______

______

Баланы (балаларны) гаиләгә вакытлыча тапшыру өчен мотивлар ______

______

Гражданин тарафыннан тәкъдим ителгән документларда ______,

(фамилия, исем, әтисенең исеме (булган очракта)

баланы (балаларны) аның гаиләсен вакытлыча тапшыру өчен каршылыклы хәлләр булу

______

(юк/бар конкрет хәлләрне күрсәтеп)

Гражданин гаиләсенә баланы (балаларны) аның гаиләсен вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә ______

______

(фамилия, исем, әтисенең исеме (булган очракта)

______

( мөмкин/гражданинның торак бинасында тормыйча мөмкин/ мөмкин түгел сәбәпләрне күрсәтеп)

| ______ | ______ | ______ |
|---|---|---|
| (Россия Федерациясе субъекты опека һәм попечительлек органының яки җирле үзидарә органының вәкаләтле вазыйфаи заты (әгәр дә Россия Федерациясе субъекты законнары белән җирле үзидарә органнары | (имза) | (Ф.И.О.) |

федераль законнар нигезендә опека
һәм попечительлек буенча вәкаләтләр
тапшырылган булса)

М.У.

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Сабирҗанов Р.Р.ка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

________________________